**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2021 Чирмешән авылы № 254

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 15 октябрендәге 418 номерлы карары белән расланган «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» на үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 15 октябрендәге 418 номерлы карары белән расланган «Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» на түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.15п. түбәндәгеләрне төшереп калдырырга:
«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ), КФҮнең читтән торып эшләү урыннары аша муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырылмый»

1.2. 5 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә: «5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләрнең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) предметы

5.1. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, берничә муниципаль хезмәт күрсәтүгә запросны (комплекслы запрос) теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районының норматив хокукый актларында тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедә кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләбе;

7) Палатаның, муниципаль хезмәт күрсәтүче Палатаның вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮнең хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларның яисә белешмәләрнең мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә таләп итү;

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче Палатага, КФҮкә, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Мәгълүмати технологияләр һәм элемтә дәүләт идарәсенең цифрлы үсеш министрлыгына (алга таба - КФҮ гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль

законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче палата җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр район башкарма комитетына бирелә һәм турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала. КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр шушы КФҮ җитәкчесенә тапшырыла. КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ гамәлгә куючы яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче палатаның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче палата җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче палатаның рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм яки региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм яисә региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны тупларга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәрнең, 210-ФЗ Федраль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар, йә мөрәҗәгать итүченең - юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) палатаның, муниципаль хезмәт күрсәтүче палатаның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәр, КФҮ, КФҮ хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүче палатаның, муниципаль хезмәт күрсәтүче палатаның вазыйфаи заты, яисә муниципаль хезмәткәр, КФҮ, КФҮ хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәве турында дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда), йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.
6. Органга кергән шикаять гариза кергән көннән бер көн эчендә теркәлә.
Муниципаль хезмәт күрсәтүче палатага, КФҮ, КФҮне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (булганда) килгән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче палатага, КФҮгә, 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән йә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять белдерелгән очракта - теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә.
7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:
1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;
2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.
8. 7 пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.
8_1. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта, муниципаль хезмәт күрсәтүче Палата, КФҮ яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарырыга кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.
8_2. Шикаятьне әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.
9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составының билгеләре ачыкланса, әлеге статьяның 5.2 пункты нигезендә шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.
1.3. 1 нче кушымта. Җир кодексыннан өземтәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеге гражданга яки юридик затка вәкаләтле орган карары нигезендә бушлай милеккә бирелә түбәндәгеләрне тапшырган очракта:
1) пунктча үз көчен югалтты - 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон - алдагы редакцияне карагыз;
2) мондый җир кишәрлегендә урнашкан дини яки хәйрия әһәмиятендәге биналар яки корылмалары милкендә булган дини оешманың җир кишәрлеге;
3) территорияне ызанлау проекты нигезендә төзелгән һәм гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару яисә яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булган җир кишәрлеген, мондый территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре булган затларга әлеге участоклар мәйданына пропорциональ булган гомуми өлеш милкенә;
4) җир кишәрлеген әлеге Кодексның 39_10 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы нигезендә гражданга түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирелгән көннән биш ел үткәннән соң, әлеге граждан мондый җир участогын күрсәтелгән чорда рөхсәт ителгән куллану нигезендә файдаланган очракта;
5) җир кишәрлеген әлеге Кодексның 39_10 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы нигезендә гражданга түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирелгән көннән биш ел үткәннән соң, әлеге граждан әлеге җир участогын күрсәтелгән чорда рөхсәт ителгән куллану нигезендә файдаланган һәм муниципаль берәмлектә һәм Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча төп эш урыны буенча эшләгән очракта;
6) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә җир кишәрлеге бирү. Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мондый гражданнар торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торырга тиеш яисә мондый гражданнарның аларны әлеге исәпкә кую өчен нигезләре бар, шулай ук мондый гражданнарга аларның ризалыгы белән җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү урынына торак урыннары белән тәэмин итү буенча социаль ярдәмнең башка чараларын бирү мөмкинлеге билгеләнергә мөмкин, дигән таләп каралырга мөмкин.
7) әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән аерым категориядәге гражданнарга һәм (яисә) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга, федераль законнарда каралган очракларда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда гражданнарның аерым категорияләренә җир кишәрлеге;
8) дини оешмага даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән җир кишәрлеге, бу оешмага Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда;
9) җир участогын гражданинга "Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга бирү үзенчәлекләре

турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә;
10) "Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында" 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җир кишәрлеге;
11) "Инновацион фәнни-технологик үзәкләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон нигезендә төзелгән фондка, инновацион фәнни-технологик үзәк территориясе чикләренә кертелгән җир кишәрлеге.
1.4. 2.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:
Вәкаләтле орган дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә бирүдән баш тарту турында карарны түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да булганда кабул итә:
1) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә сату үткәрмичә җир кишәрлеге алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать итте;
2) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән, киләсе очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә әлеге Кодексның 39_10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән;
3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә төзелгән, түбәндәге очраклардан тыш, әлеге ширкәт әгъзасы (әгәр мондый җир участогы бакча яки яшелчә өчен булса) яисә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре (әгәр җир участогы гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булып торса) мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән;
3_1) пунктча өстәмә рәвештә 2019 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелде; 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон үз көчен югалтты - алдагы редакцияне карагыз;
4) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада гражданнар яисә юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, киләсе очраклардан тыш, әгәр җир кишәрлегендә урнаштыруы сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки әлеге Кодексның 39_36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бинага, корылмага, алардагы бүлмәләргә, әлеге төзелеп бетмәгән объектка хокук иясе мөрәҗәгать иткән, шулай ук җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән һәм анда урнашкан биналарга, корылмаларга, төзелеп бетмәгән объектларга карата үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында карар яки үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләр нигезендә һәм күрсәтелгән карарларда билгеләнгән срокларда туры китерү турында карар кабул ителгән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55_32 статьясындагы 11 өлешендә каралган вазыйфалар үтәлмәгән;

5) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризадагы җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, түбәндәге очраклардан тыш, әгәр җир кишәрлегендә урнаштыруы сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки әлеге Кодексның 39_36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бинага, корылмага, алардагы бүлмәләргә, әлеге төзелеп бетмәгән объектка хокук иясе мөрәҗәгать иткән;
6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынып яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта рөхсәт ителми;
7) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган булып тора, әгәр дә мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә, даими (сроксыз) файдалануга бирү турында гариза белән яки җир кишәрлеген резервлау турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артып киткән вакытка җир кишәрлеген арендага, түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса, резервлау максатлары өчен җир кишәрлеге бирү очракларыннан тыш;
8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, түбәндәге очраклардан тыш, әгәр җир кишәрлеге бирү турында гариза белән, мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объект милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенә ия булучы мөрәҗәгать иткән булса;
9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территория чикләрендә урнашкан, аңа карата башка зат белән территорияне комплексны үстерү турында шартнамә төзелгән, яисә җир участогы башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, түбәндәге очраклардан тыш, әгәр мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән булса һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектлар төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать итте;
10) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплексны үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, түбәндәге очраклардан тыш, әгәр җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән булса, ул әлеге затның күрсәтелгән объектлар төзү буенча йөкләмәсен күздә тота;
11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында белдерү әлеге Кодексның 39_11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата әлеге Кодексның 39_11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату буенча аукцион яисә аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза керде, түбәндәге шартлар булганда, мондый җир кишәрлеге әлеге Кодексның 39_11 статьясындагы 4 пунктының 4 пунктчасы нигезендә төзелгән һәм вәкаләтле орган әлеге Кодексның 39_11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итмәгән очракта;
13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата әлеге Кодексның 39_18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында белдерү басылып чыкты һәм урнаштырылды;
14) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлегеннән файдалану максатларына туры килми, расланган территорияне планлаштыру проекты нигезендә линияле объект урнаштыру очракларыннан тыш;
14_1) сорала торган җир кишәрлеге тулысынча территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, анардагы җир кишәрлекләрен куллануга билгеләнгән чикләүләр җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт итмиләр;
15) соратып алына торган җир кишәрлеге, әлеге Кодексның 39_10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән;
16) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтенә җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы әлеге Кодексның 39_10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән чик күләмнән артып китә;
17) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать итте;
18) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмалар төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;
19) җир кишәрлеген билгеләнгән хокук төрендә бирү рөхсәт ителми;

20) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;
21) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер категориягә кертелмәгән;
22) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата гамәлдә булу вакыты чыкмаган аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителде, һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;
23) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынды һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган максатларга туры килми, мондый җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;
24) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләре "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;
25) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы аның җир участогының урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яисә урман кишәрлекләренең проект документларында күрсәтелгән мәйданнан артып китә, алар нигезендә мондый җир участогы ун проценттан артык төзелгән;
26) "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт милке исемлегенә яисә муниципаль милек исемлегенә кертелгән җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән кече һәм урта эшкуарлык субъекты булмаган зат яисә күрсәтелгән Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган зат мөрәҗәгать итте.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) .

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин